ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Арча муниципаль районы
Утар Аты авыл җирлеге
башкарма комитеты

422017, Арча муниципаль районы
Утар Аты авылы, Кооператив урамы, 22
тел. 50-4-22, 50-3-31

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Арский муниципальный район
Исполнительный комитет
Утар-Атынского сельского поселения

422017, Арский муниципальный район
с.Утар-Аты, ул. Кооперативная, 22
тел. 50-4-22, 50-3-31

# Карар

01 апрель 2016
___________________________ел №_3

**ТР Арча муниципаль районы
Утар-Аты авыл җирлегендә
санитар-экологик хәлне яхшырту
буенча чаралар үткәрү турында**

Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2016 елның 23 мартындагы 322 номерлы карарын үтәү йөзеннән һәм Арча муниципаль районы «Утар Аты авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен санитар чистарту мәсьәләсен хәл итү һәм аны халыкның санитар-эпидемиологик һәм экологик иминлегенә җавап бирә торган халәткә китерү максатыннан, Утар Аты авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Утар Аты авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 2016 елның 01 апреленнән 31 маена кадәр торак пунктларны, территорияләрне, предприятиеләрне төзекләндерү, яшелләндерү, санитар-экологик хәлен яхшырту буенча икеайлык игълан итәргә (алга таба - икеайлык).

2. Икеайлык үткәрү эшләрен координацияләү өчен комиссия төзергә һәм аның составын 1 нче кушымта нигезендә расларга.

3. 2016 елга «Утар Аты авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә санитар-экологик хәлне яхшырту буенча беренче чираттагы чаралар планын расларга (2 нче кушымта).

4. Утар Аты авыл җирлеге депутатларына көнкүреш, чишмәләр, зиратлар, дини объектларны беркетергә ( 3 нче кушымта).

5. Тәкъдим итәргә:

- «Игенче», «Тукай» АФ «Идель» агрофирмасы җитәкчесенә, «Нива-Агро» ҖЧҖ директорына, Утар Аты урта мәктәбе директорына, балалар бакчалары, кибетләр, ФАПлар мөдирләренә, мәдәният һәм клуб йортлары директорларына үз хуҗалыклары һәм алар янәшәсендәге кишәрлекләрдә агач һәм куаклар утырту, йортлар фасадларын ремонтлау, урамнарны яктырту, зиратларны, балалар һәм спорт мәйданчыкларын, азык-төлек кибетләрен төзекләндерү, каты көнкүреш калдыкларын вакытлыча складлау урыннарында чүп-чар чыгару буенча махсус техника эшен тәэмин итәргә.

- Икеайлык үткәрү буенча комиссияләр Утар Аты авыл җирлеге Советының 2014 елның 8 апрелендәге 58 номерлы карары белән расланган Арча муниципаль

районы «Утар Аты авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен тышкы төзекләндерү, җыештыру, чистартуны оештыру, чисталыкны һәм тәртипне тәэмин итү кагыйдәләрен үтәү буенча урамнарның, торак йортлар, предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр, сәүдә нокталарының торышын тикшерүне оештыру, тикшерү материалларын Арча муниципаль районы башкарма комитеты каршындагы административ комиссиягә һәм Арча хәбәрләре газетасы редакциясенә җибәрергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Утар Аты авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе А.Г. Хәкимжанов

*Утар Аты авыл җирлеге*
*Башкарма комитетының*
*2016 елның 1 нче апрелендәге*
*3 нче номерлы карарына*
*1 нче кушымта*

2016 елга Арча муниципаль районы Утар Аты авыл җирлеге Утар Аты, Орнашбаш, Югары Аты, Кушлавыч, Иске Җөлби авыллары буенча санитар-экологик хәлне яхшырту буенча икеайлык үткәрү комиссиясе составы

Утар Аты, Орнашбаш авылларында:

Хәкимҗанов А.Г. - Утар Аты авыл җирлеге башлыгы

Касыймов Р.Т. Район Советы депутаты

Гомәрова Г.Г. - Орнашбаш мәдәният йорты директоры

Якупов И.Н -Орнашбаш округы депутаты

Гыйниятуллина Г.Г. - Утар Аты төп гомуми белем бирү мәктәбе директоры

Югары Аты, Субаш Аты авылларында:

Галимҗанова Г.А. - башкарма комитет секретаре

Вафина Г.А.- Депутат, Субаш Аты төп гомуми белем бирү мәктәбе директоры

Хафизов С.С.- Югары Аты мәдәният йорты мөдире

Кушлавыч, Иске Җөлби авылларында:

Минһаҗева С.С. Утар Аты башкарма комитеты белгече

Гайнуллин И.И. Кушлавыч мәктәбе директоры, депутат

Хәнәфиева Ф.Н Кушлавыч авылы клубы мөдире

*Утар Аты авыл җирлеге*
*Башкарма комитетының*
*2016 елның 1 нче апрелендәге*
*3 нче номерлы карарына*
*2 нче кушымта*

## 2016 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Утар Аты авыл җирлеге башкарма комитетындагы санитар-экологик хәлне яхшырту буенча икеайлык чаралар планы

| № | Чара исеме | Үтәлү вакыты | Башкаручылар |
|---|---|---|---|
| 1 | Чишмәләрне, азык-төлек кибетләрен, зиратларны төзекләндерү буенча чаралар үткәрү | 20.04.2016 | Авыл җирлеге, мәктәп |
| 2 | Агач, куаклар, чәчәкләр утырту һәм аларны киртәләү | 25.04.2016. | Авыл җирлеге, мәктәп |
| 3 | Коймаларны ремонтлау, буяу | 26.04.2016 | Авыл җирлеге, мәктәп |
| 4 | Авыл торак пунктларында каты көнкүреш калдыкларын вакытлыча җыю урыннарын карап тоту буенча чаралар үткәрү, калдыкларны җыю, туплау һәм юкка чыгару | 30.04.2016 | Авыл җирлеге. мәктәп |
| 5 | Торак пунктлар территорияләрендә санкцияләнмәгән чүплекләрне ябу, әлеге урыннарны тыю аншлаглары белән җиһазландыру | 01.05.2016 | Авыл җирлеге «Игенче» агрофирмасы ҖЧҖ, Тукай ҖЧҖ |
| 6 | Аларны киртәләү һәм кисәтү аншлаглары урнаштыру эшләрен башкарып, югалган себер түләмәсе үләксә базларының төгәл урнашу урыннарын билгеләү | 11.05.2016 | «Игенче» агрофирмасы» ҖЧҖ, Тукай |
| 7 | Орнашбаш, Утар Аты авылларындагы чишмәләрне төзекләндерү, су белән тәэмин итү, тукталышларны, аншлагларны ремонтлау | 15.05.2016 | Авыл җирлеге, мәктәп |
| 8 | Иң төзек авылга, оешмага, урамга, ишегалды, йортка конкурс оештыру | 31.05.2016 | Авыл җирлеге |

*Утар Аты авыл җирлеге*
*Башкарма комитетының*
*2016 елның 1 нче апрелендәге*
*3 нче номерлы карарына*
*3 нче кушымта.*

## Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Утар Аты авыл җирлеге территориясендә агач утыртуны оештыру буенча якынча план

| № | Оешма исеме | Барлыгы | | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| | | үсентеләр | Чәчәкләр (сортлар) | |
| 1 | Утар Аты төп гомуми белем бирү мәктәбе | 60 | 10 | Сорнар, |
| 2 | Субаш Аты башлангыч мәктәбе | 20 | 5 | Сорнар, |
| 3 | Орнашбаш мәктәбе | 20 | 5 | Сорнар, Арча урман хуҗалыгы |
| 4 | Халык | 90 | 8 | |
| 5 | Утар Аты Мәдәният йорты | 10 | 5 | |
| 6 | Субаш Аты авыл клубы | 10 | 5 | |
| 7 | Утар Аты балалар бакчасы | 10 | 5 | |
| 8 | Кибетләр | 10 | 10 | |
| 9 | Утар Аты ФАП | 5 | 5 | Арча урман хуҗалыгы |
| 10 | Кушлавыч мәктәбе, клубы | 40 | 5 | Арча урман хуҗалыгы |
| 11 | Кушлавыч авыл клубы | 10 | 5 | Арча урман хуҗалыгы |
| 12 | Югары Аты авылы мәдәният йорты, мәктәбе, | 20 | 5 | Арча урман хуҗалыгы |

*Утар Аты авыл*
*җирлеге*
*Башкарма комитетының*
*2016 елның 1 нче апрелендәге*
*3 нче номерлы карарына*
*4 нче кушымта.*

## Социаль объектлар буенча эшләрне бүлү

| № | Башкаручылар | Билгеләнгән участоклар | Үтәү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Утар Аты мәктәбе | Мәктәпкә юл, һәйкәл | 06.04.2016 | Гыйниятуллина Г.Г. |
| 2. | Утар Аты ДС | "Әниләр чишмәсе", "Паровой чишмәсе" | 06.04.2016 | Сөләйманов Ф.М. |
| 3 | Утар Аты мәктәбе, китапханә, почта, ФАП, башлангыч сыйныфлар, мәдәният йортлары. | Мәчет, авыл территориясе. | 07.04.2016 | Сабирова Ф.<br>Миңнуллина Ф.Ф.<br>Г.Моратов<br>Галимҗанова Р. |
| 4 | Орнашбаш клубы, мәктәбе | Мәчет, һәйкәл, кышкы вакытта күпергә юл, зиратка юл | 08.04.2016 | Сабирова Э.М.<br>Әхмәтов Ф.З |
| 5 | Орнашбаш клубы, китапханә | Авыл территориясе, чишмә | 09.04.2016 | Гомәрова Г.Ю.<br>Гәрәева В.Г. |
| 7 | Югары Аты мәктәбе, бакча, авыл клубы. | Һәйкәл, парк, авыл территориясе | 10.04.2016 | Шәйхетдинова А.В.<br>Нәгыймова Ф.Р.<br>Хафизов.С. |
| 8 | Югары Аты клубы, ФАП | Чишмә, күпер, авыл территориясе | 10.04.2016 | Хафизов С.С.<br>Галимҗанова Ф.В. |
| 9 | Абдрахманов Илнур | Югары Аты , Субаш-Аты шугалагы | 10.04.2016 | Абдрахманов И.Ф. |
| 10 | Субаш Аты мәктәбе | Һәйкәл, монумент авыл территориясе | 11.04.2016 | Вафина Г.А. |
| 11 | Субаш-Аты, авыл клубы, китапханә | Мәчет, авыл территориясе | 11.04.2016 | Нәгыймова С.Р.<br>Касыймова Л.Ш. |
| 12 | Кушлавыч мәктәбе | Тукай һәйкәле авыл территориясе, күпер, чишмәләр | 06.04.2016 | Гайнуллин И.И. |
| 13 | Кушлавыч китапханәсе, ФАП | Мәчет | 06.04.2016 | Фәттахова Р.Г.<br>Заббарова Т.Ф.<br>Әюпова Р.Г. |
| 14 | Кушлавыч музее | зират | 06.04.2016 | Мөхәммәтшина Л.А. |